КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 октябрь г.Казань № 1036

2025 елга Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында

«Транспорт чараларын техник тикшерү турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1434 номерлы карары, Федераль антимонополия хезмәтенең 2022 елның 30 июнендәге 489/22 номерлы боерыгы белән расланган Техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмен исәпләү методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмен кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләү турында» 2023 ел, 27 ноябрь, 1521 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин